# Син дә татарча сөйләш!

* Гафиятуллин  Газинур Гафиятулла улы
*Аның  гомер – үзе бер тарих
*Уңышларыбыз



**ГЫЙНВАР, 2018**



# ГАФИЯТУЛЛИН ГАЗИНУР ГАФИЯТУЛЛА УЛЫ

ГАФИЯТУЛЛИН Газинур Гафиятулла улы (13.1.1913, Самара губернасы, Бөгелмә өязе Сугышлы авылы- 14.1.1944, Псков өлкәсе, Великие Луки районы Овсище авылы, Мякотино авылында җирләнә), Советлар Союзы Герое (4.6.1944, үлгәннән соң), сержант. Колхозда, урман сәнәгате хуҗалыгында эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 20 нче укчы полкның (22 нче армиянең 37 нче укчы дивизиясе) отделение командиры урынбасары. Көнбатыш, Калинин, Төньяк-Көнбатыш, Балтыйк буе һәм 2 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Дрисса һәм Витебск чигендә оборона сугышларында (1941), Смоленск сугышында (1941), Калининград (1941) һәм Ржев-Вязьма (1943) оборона операцияләрендә, Холм һәм Великие Луки шәһәрләре янында Ловать елгасы өчен барган бәрелешләрдә катнаша. 1944 нең 14 гыйнварында Овсище авылы өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: отделение белән бергә дошман дзотын юк итә, икенче дзотның амбразурасына ташлана һәм утны күкрәге белән каплап һәлак була. Бөгелмә шәһәрендә һәм Овсище авылында Гафиятуллинга һәйкәл куела. Геройның исеме Казан, Бөгелмә, Лениногорск, Әлмәт урамнарына бирелә.



# Аның гомер – үзе бер тарих

***Без укучыларга уткэнебез,тарихыбыз турында еш сөйлибез. Чөнки яшәеш тәнфибәсе күрсәткәнчә, үткәннәрне белмәгәннен киләчәге дә юк.***

Шакирҗан Мөхәммәтҗанов, ягъни Александр Матросовның (балалар йортында аның исемен алыштырган булганнар) батырлыгын кабатлаган якташыбыз, Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин - шәһәребезнең генә түгел, ә бөтен татар милләтенең Россия халкының горурлыгы.

Димәк, каһарманның үзе турында да, аның якыннары турында да без күбрәк белергә тиеш.

Үткән ел 9 Майда без укучылар белән Сугышлы авылындагы музейда булып кайткан идек.

Музейдан кайткач, укучылар белән герой- якташыбызның  хатыны - Гыйльмурый әби янында да булдык. Ул безгә ире турында бик күп мәгълүмат бирде. Сугыш чоры вакытындагы, аннан соңгы тормыш авырлыклары турында сөйләде. Яшь вакытындагы фотосын да күрсәтте: “Мин аз генә үзгәрмәгәнмен, әйеме? Яшь бит әле мин - гыйнвар аенда миңа нибары 100 яшь кенә тулачак”, - дип шаяртты әби ул вакытта. Ә без, үз чиратыбызда, әбинең бу олуг юбилеена килергә сүз биреп, кайтып киттек.

Әйткән сузебезгә тугрылык саклап, быел кышкы каникулдан чыккач,  җыендык та, укучылар белән бергәләп, батыр якташыбызның хатынын - хәзер инде йөзьяшәр Гыйльмурый әбине тәбрикләргә дип, аның өенә бардык.

Кызганычка каршы, без беркадәр соңга да калган булып чыктык  безгә кадәр Азнакай, Лениногорскидан инде олы кунаклар килеп, әбине котларга да өлгергәннәр.

Әйе, чын мәгънәсендә, ил горурлыгы булган каһарманның җәмәгатенә 100 яшь тулу - гадәти туган көн генә түгел, бер гасырлык юбилей бит ул! Аның язмышы, узган гомер юлы үзе бер тарихка тин. Шуңа да хәтта чит районнардан олуг кунакларның  килүе бер дә гаҗәп түгел.

Буген дә шаян сүзле, җор телле әбиебез укучылар белән рәхәтләнеп сөйләште, барыбызга да ин изге теләкләрен җиткерде.

Гыйльмурый әби кызлары Роза белән Римма тәрбиясендә яши. Әнвәр абый да әнисе янында еш була. Әби - барлыгы сигез бала анасы (Газинурдан өч бала белән калган Гыйльмурый, сугыштан соң Исрафил Ибраһимов белән гаилә корып, тагын биш бала табып үстерә). Бүгенге көндә әби сокланырлык бай кеше - 16 оныгы, 31 оныкчыгы бар.

Гыйльмурый әби без килгәнгә ничек шат булса, без д аның белән очрашудан зур канәгатьлек хисе алып, каһарман якташыбыз турында кызыклы мәгълуматларга баеп, юбилярның үз язмышы турында да гыйбрәтле вакыйгалар сөйләгәннәрен тыңлап, ә тагын инде бер гасыр гомер итүче әбинең бүген дү куңел көрлеген җуймыйча, ачык зиһенле, күтәренке күңелле булуына, яшәүдән тәм таба белүенә сокланып, аның үрнәгендә канатланып кайттык.

**Эльвира Ситдыйкова, бнчы мәктәп укытучысы.**
Автор һәм Румия Хафизова фотолары







Гыйльмури әби малае белән

# Уңышларыбыз




Победитель 3 степени
Республиканского конкурса научно-исследовательских и творческих работ
«Мой Татарстан»
Хафизовф Айгуль
Ученица 11В класса
Учитель: Ситдикова Э.А.






Победитель 2 степени
Республиканского конкурса научно-исследовательских и творческих работ
«Мой Татарстан»
Кашапова Луиза
ученица 10В класса
Учитель: Хафизова Р.А.



Победитель муниципального этапа
Республиканской олимпиады школьников по татарскому языку
Муратова Динара
ученица 9А класса
Учитель: Хафизова Р.А.



Победитель муниципального этапа
Республиканской олимпиады школьников по татарскому языку
Узум Сема
ученица 6А класса
Учитель: Хафизова Р.А.

Победитель
муниципального этапа
Республиканской олимпиады
школьников по татарскому языку
Ефремова Анна
ученица 6 класса
Учитель: Юсупова Л.А.





Победитель
муниципального этапа
Республиканской олимпиады
школьников по татарскому языку
Нигматуллина Айгуль
Ученица 5В класса
Учитель: Хазипова Г.Д.



Лобачева Арина,4а



Широкова Ангелина,4а



Назарова Арина,4а




Фаррахова Милена,4а

# Буран

**Урамда – буран,**
**Мин өйдә торам.**
**Тәрәзә аша**
**Тик авыз ерам.**
**Әй, җил выжылдый,**
**Буран дуылдый.**
**Ачулы песи**
**Кебек мырылдый.**
(Г.Толымбай)



Абдуллин Артур,4а



Каримов Данияр,4а



Нестерова Таисия,4а



Зареева Кира,4а

Бөгелмә шәһәре Татарстан Республикасы
муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче
6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе

7нче А сыйныфы укучылары һәм
туган тел һәм әдәбияты укытучылары